РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Микулинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский район,
с.Микулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башлыгы

Советская ур., 74 йорт, Азнакай районы,
Микулино авылы, 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «05»ноября 2025г.** **№ 8**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Благодатный торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм: :

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Благодатный торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 21 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Благодатный торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 21 ноябрендә 16.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр

- гражданнар җыенын уздыру урыны – Благодатный бистәсе, Солнечная ур., 7 й.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә.:

-2025 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә:

Микулино авылы, Совет ур., 74 йорт, Благодатный бистәсе, Солнечная ур., 7 йорт;

- сайлау хокукына ия Благодатный бистәсендә яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Благодатный бистәсе халкына массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар буенча гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Благодатный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда үзара салымны кертүгә 500 сум күләмендә ризамы? 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар өчен 250 сум күләмендә, күпбалалы гаиләләрнең һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:

- ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зираттан чүп чыгару ).

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урман урамында чокырларны ремонтлау, сатып алу, ташу, вак таш салу).

- Пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту) .

“ КАРШЫ” “РИЗА”

5 .Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//Aznakayevo. tatarstan. ru адресы буенча һәм Микулино авылы, Совет ур., 74 йорт, Благодатный бистәсе, Солнечная ур., 7 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Башлык: И.А.Такиулин